СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы, Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 16 » июль 2021 ел** **№ 28**

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 9.1 номерлы карары белән расланган Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021елның 30 апрелендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 03.11.2015 9.1 номерлы карары белән расланган Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен эш сәфәренә җибәрү белән бәйле чыгымнарны каплау тәртибен һәм күләмнәрен билгели.».

Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре (алга таба - Хезмәткәрләр) дип муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затлары, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифалары булмаган вазифалар биләүче хезмәткәрләр, шулай ук Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче затлар аңлашыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин